**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22 chishma@tatar.ru

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
## КАРАРЫ

2015 елның «12» февраленнән № 41-239

### «2015 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Яңа Чишмә муниципаль районы Уставы, Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен Яңа Чишмә муниципаль районына «Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында килешүләр нигезендә Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2015 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карар «Шешминская Новь», «Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасында һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында бастырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Советының
2015 елның 12 февралендәге
41-239 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2015 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (кушымта итеп бирелә).**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

2015 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) (алга таба – прогноз планы) «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон,Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары белән расланган Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турында нигезләмә нигезендә эшләнде.

## 2. Хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек

2015 елда түбәндәге муниципаль күчемсез милек хосусыйлаштырылырга тиеш.

**2015 елда ачык аукционнарда сату юлы белән хосусыйлаштырылырга тиешле Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан җир һәм мөлкәтләр исемлеге**

| т/б | Муниципаль милек исеме | Урнашкан урыны | Мәйданы, кв. м. | Хосусыйлаштыруның планлаштырылган вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Аш бүлмәсе бинасы һәм җир кишәрлеге | Яңа Чишмә муниципаль районы, Зирекле авылы, Колхоз урамы, 18 | 71,0 | 2015 елның 2 кварталы |
| 2 | Производство бинасы һәм җир кишәрлеге | Яңа Чишмә муниципаль районы, Чуваш Чабаксары авылы, Пролетар ур., 19а | 458,3 | 2015 елның 2 кварталы |
| 3 | Хуҗалык корылмалары | Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Шмидт ур., 25 | 175 | 2015 елның 2 кварталы |
| 4 | Сарай бинасы | Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Октябрь ур., 76 | 17,7 | 2015 елның 3 кварталы |
| 5 | Сарай бинасы | Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Октябрь ур., 76 | 12 | 2015 елның 3 кварталы |
| 6 | Мунча бинасы | Яңа Чишмә муниципаль районы, Яңа Чишмә авылы, Октябрь ур., 76 | 17,6 | 2015 елның 3 кварталы |